ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

12.12.2023 | с. Большие Меми | № 75

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-

### Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым җыю тәртибе турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Уставы нигезендә Олы Меми авыл җирлегенең 2022 елның 10 ноябрендәге 1 номерлы торак пунктларында гражданнар җыенында кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районының
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г. А. Фомина

Олы Меми авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2023 елның 12
декабреннән 75 номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегендә
гражданнардан үзара салым җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 1.01.2024 елдан 25.03.2024 елга кадәр гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:
а) мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары.

4. Түләүләр күләме гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:
а) уку йортлары студентлары,
б) күп балалы гаиләләр.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.
Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки кечерәйтелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Гражданнар түләүләрне физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисаплар башкару хокукына ия булган оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/. сылтама буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша күчерү юлы белән башкара ала.

8. Түләү фактын раслау булып керем касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

9. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Олы Меми авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2023 елның 12
декабреннән 75 номерлы карарына
2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________

Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү турында

Түләүченең Ф.И.А.и.
___________________________________________________________________
Адрес: _________________________________________________________
__________________________________________________________ нигезендә
сезгә ______ кадәр чараларны гамәлгә ашыру өчен _____ күләмендә
түбәндәге реквизитлар буенча:
____________________________________________________________бер тапкыр
түләү түләргә кирәк.
Алучының банкы БИК ___________________________________________
Сч. № __________________________________________________
Алучы __ Сч. № __________________________________________
ИНН ____________________________________________
КПП ___________________________________________
КБК _______________________ОКАТО ______________________
Түләү билгеләү
______________________________________________________________________

Җитәкче ________________________________________________
М. у. (имза) (имзаны киңәйтеп язу)
- - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - -
Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне бюджетка түләү турында
__________________
(муниципаль берәмлек исеме)
________________ сум күләмендә.

Түләүченең Ф.И.А.и. _____________________________
Адрес: ________________________________________________

Алдым "__" ___________________ 20____ ел _ ___________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Әгәр хәбәр түләүчегә шәхсән тапшырыла икән, киселә торган өлеше тутырыла һәм Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.